**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы һәм 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларының III кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Һәвәскәрләр авы һәм спорт авының түбәндәге срокларын билгеләргә:

соры куянга – 15 октябрьдән 10 гыйнварга кадәр;

чәшкегә, тиенгә, янутсыман эткә, сусарларга, көзәннәргә – 15 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

су, сазлык-болын, кыр һәм дала җәнлекләренә – җәйге-көзге ау сезоны чорында сентябрьнең беренче шимбәсендә 17 сәгатьтән 15 ноябрьгә кадәр;

тәлләтәвечкә – көзге-кышкы ау сезоны чорында сентябрьнең беренче шимбәсендә 17 сәгатьтән 31 декабрьгә кадәр;

сазлык-болын җәнлекләренә – җәйге ау сезоны чорында ау этләре белән 25 июльдән 15 августка кадәр.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Барлык аучылык биләмәләрендә 2022 елга кадәр байбакка һәвәскәрләр авы һәм спорт авы оештыру тыела.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 19 февраль
№ ПУ-130